ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.03.2023 с.Старое Дрожжаное № 109

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Гамәлдәге муниципаль хокукый актларны федераль законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 631-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 мартындагы 135 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында мәгариф өлкәсендә вәкаләтләр бүлешү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**3.27 пунктына** түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

«- гамәлгә ашырыла торган белем бирү программалары буенча мәгариф эшчәнлегенең дәүләт аккредитациясе булу-булмавы турында;»;

**3.28 пунктының дүртенче абзацын** төшереп калдырырга.

2. «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 07 апрелендәге 187 номерлы карары (12.10.2022 № 529 редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булганнарны исәпкә кую, яңадан теркәү һәм исәпкә алу эшенә үзгәрешләр кертү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының **1.5 пунктының бишенче абзацында** «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы

нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 13 февралендәге 79 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында финанс-бюджет өлкәсендә тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенең **5 пунктының 2 абзацында** «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе в.б. И.Р. Измайлов